■ Белгәндәребеҙ дөрөсме?

# ГОСЕЛ ТӘҺАРӘТЕ ХАҠЫНДА КАБАТЛАУ

**Нәрсә ул госел?**

Бөтен тәнне энә очы калмаслык рәвештә юуга госел диелә.

**Нәрсә ул җөнеплек хәле?**

җөнеплек хәле - ир кешеләрнең мәниләре шәһвәт белән бушалу (оргазм)аркасында чыгып барлыкка килгән мәгънәви пычраклык хәле. Бу хәлдән тик госел кыену белән котылырга мөмкин.

**Нәрсә ул хәез һәм нифас?**

Хәез хәле - хатын-кызларның ай саен булган, уртача бер атна, ун көн дәвам итә торган күрем хәлләре. Ә нифас - йөкле хатынның бала тапканнан соң лохусалык вакыты. Хәез һәм нифас аркасында килгән кан сәбәпле хатын-кызлар кайбер гыйбадәтләрне кыла алмаслар. Ләкин бу хәлләрнең бетүеннән соң госел коенып, бу гыйбадәтләрен дәвам итә алалар.

**Госел коенуның исәнлеккә нинди файдалары бар?**

Госел тәһарәтенең мәгънәви файдаларыннан башка матди файдалары да бар. Шул сәбәпле ислам дине госел тәһарәтенә бик әһәмият биргән. Госелнең кешенең исәнлеге өчен файдалары шулай ачыклана: шәһвәт белән бушалу вакыйгасы (шәһвәт булу - кеше тәнендәге бөтен нерваларны хәрәкәт иттерә торган һәм бөтен организмны калтырата торган физиологик вакыйга) барлыкка килгән вакытында тәндәге күзәнәкләрдә җимерелү барлыкка килер. Тын алу һәм канның йөрүе бу вакыйгага бөтен көчләре белән катнашкан өчен, тын алу арта башлар.

Шулвакыт кеше кулланган энергия кинәттән 1500 метрга йөгергән кешенең энергиясе белән бертигез. Шул сәбәпле кешенең тәне бик арып китәр. Кешенең тәне тик юыну аркасында бу хәлдән котылыр, җанланыр һәм көчәер.

Шуның өчен госел матди һәм мәгънәви ял итү һәм тәнгә тынычлык бирә торган бер юыну.

**Госел коену кайчан кирәк була?**

Кешедә шул ике хәлдән берсе барлыкка килсә, госел коенырга тиеш:

1. Җөнеплек хәле (госелсезлек)
2. Хатын-кызларның хәез һәм нифас хәлләре беткәннән соң.

**Госелнең ничә фарызы бар?**

Госелнең фарызы өч.

1. Авызны чайкау.
2. Борын эчен юу.
3. Бөтен тәнне коры урын калмаслык рәвештә юып пакьләү.

Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Йомадиәл әүүәл 2011 миләди йыл**
**1432 һижри йыл.**

| Йомадиәл әүүәл | Аҙна көндәре | Апрель, май | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дүшәмбе | 4 | 6.14 | 7.44 | 14.30 | 19.25 | 20.55 | 22.25 |
| 2 | Шишәмбе | 5 | 6.11 | 7.41 | 14.30 | 19.27 | 20.57 | 22.27 |
| 3 | Шаршамбы | 6 | 6.09 | 7.39 | 14.30 | 19.29 | 20.59 | 22.29 |
| 4 | Кесе йома | 7 | 6.06 | 7.36 | 14.30 | 19.31 | 21.01 | 22.31 |
| 5 | Йома | 8 | 6.04 | 7.34 | 14.30 | 19.33 | 21.03 | 22.33 |
| 6 | Шәмбе | 9 | 6.01 | 7.31 | 14.30 | 19.35 | 21.05 | 22.35 |
| 7 | Йәкшәмбе | 10 | 5.59 | 7.29 | 14.30 | 19.37 | 21.07 | 22.37 |
| 8 | Дүшәмбе | 11 | 5.56 | 7.26 | 14.30 | 19.39 | 21.09 | 22.39 |
| 9 | Шишәмбе | 12 | 5.54 | 7.24 | 14.30 | 19.41 | 21.11 | 22.41 |
| 10 | Шаршамбы | 13 | 5.52 | 7.22 | 14.30 | 19.43 | 21.13 | 22.43 |
| 11 | Кесе йома | 14 | 5.49 | 7.19 | 14.30 | 19.45 | 21.15 | 22.45 |
| 12 | Йома | 15 | 5.47 | 7.17 | 14.30 | 19.47 | 21.17 | 22.47 |
| 13 | Шәмбе | 16 | 5.44 | 7.14 | 14.30 | 19.48 | 21.18 | 22.48 |
| 14 | Йәкшәмбе | 17 | 5.42 | 7.12 | 14.30 | 19.50 | 21.20 | 22.50 |
| 15 | Дүшәмбе | 18 | 5.40 | 7.10 | 14.30 | 19.52 | 21.22 | 22.52 |
| 16 | Шишәмбе | 19 | 5.37 | 7.07 | 14.30 | 19.54 | 21.24 | 22.54 |
| 17 | Шаршамбы | 20 | 5.35 | 7.05 | 14.30 | 19.56 | 21.26 | 22.56 |
| 18 | Кесе йома | 21 | 5.33 | 7.03 | 14.30 | 19.58 | 21.28 | 22.58 |
| 19 | Йома | 22 | 5.30 | 7.00 | 14.30 | 20.00 | 21.30 | 23.00 |
| 20 | Шәмбе | 23 | 5.28 | 6.58 | 14.30 | 20.02 | 21.32 | 23.02 |
| 21 | Йәкшәмбе | 24 | 5.26 | 6.56 | 14.30 | 20.04 | 21.34 | 23.04 |
| 22 | Дүшәмбе | 25 | 5.23 | 6.53 | 14.30 | 20.06 | 21.36 | 23.06 |
| 23 | Шишәмбе | 26 | 5.21 | 6.51 | 14.30 | 20.08 | 21.38 | 23.08 |
| 24 | Шаршамбы | 27 | 5.19 | 6.49 | 14.30 | 20.09 | 21.39 | 23.09 |
| 25 | Кесе йома | 28 | 5.17 | 6.47 | 14.30 | 20.11 | 21.41 | 23.11 |
| 26 | Йома | 29 | 5.15 | 6.45 | 14.30 | 20.13 | 21.43 | 23.13 |
| 27 | Шәмбе | 30 | 5.12 | 6.42 | 14.30 | 20.15 | 21.45 | 23.15 |
| 28 | Йәкшәмбе | 1 | 5.10 | 6.40 | 14.30 | 20.17 | 21.47 | 23.17 |
| 29 | Дүшәмбе | 2 | 5.08 | 6.38 | 14.30 | 20.19 | 21.49 | 23.19 |
| 30 | Шишәмбе | 3 | 5.06 | 6.36 | 14.30 | 20.21 | 21.51 | 23.21 |

**Госел коену фарыз булган кешеләр кайсы гыйбадәтләрне үти алмаслар?**

Госел коену фарыз булган кешеләр, ягъни җөнеп ирләр белән хәез һәм нифас хәлендәге хатын-кызларга шул гыйбадәтләрне үтәүләре тыела.

1. Намаз уку.
2. Хәез һәм нифас хәлендәге хатын өчен ураза тоту.
3. Коръән уку (шәһадәт сүзен әйтү, сөбханаллаһ, әлхәмдулилләһ, Аллаһу әкбәр әйтү, Пәйгамбәргә салават әйтү, аять булмаган догаларны уку мөмкин).
4. Коръәнне кулга алу.
5. Кагъбәне тәваф кылу.
6. Мәчеткә керү.

Мәҗбүри хәлләрдән башка, госел коенырга тиеш булган кешенең:

1. кулларын һәм авызын юмыйча ашап эчүе;
2. дини китапларны кулларына алучы тыелмаган булса да, мәкруһ дип саналган.

**Госел тәһарәте ничек алына?**

Су аз булган вакытта, салкын яки вакытның булмаган вакытларында, ашыгып госел коенган вакытта иң баштан гаурәтләрдәге пычраклыклар пакьләнер. Шуннан соң өч мәртәбә авызга, өч мәртәбә борынга су биреп авыз һәм борын яхшылап пакьләнер. Шуннан соң башка, уң һәм сул җилкәдән су коеп бөтен тән юылыр. Коры урын калмаган вакытта, госел тәмам булыр. Бу тик госелнең фарызларын җиренә җиткерү белән алынган госел булыр.

Мөмкин булган вакытларда, янә гаурәт урыннарын юганнан соң, алдан намаз тәһарәте алына, аннары баштан, шуннан уң һәм сул җилкәдән өчәр мәртәбә су коела. Һәр су койган вакытта кул белән бөтен тән сыпырылып, суның бөтен тәнгә таралуын тәэмин итү белән мәгънәви пычраклардан башка матди пычракларның да юылуы тәэмин ителә. Бу арада тәндә энә очы кадәр булса да коры урынның калмавына игътибар кылыныр. Иң азакта пычрак суларның түгелгән урыннарга баса торган аяклар яңадан юылыр.

Госелнең шарт һәм фарызы - авыз һәм борынның эч яклары белән тәннең бөтенесендә коры урынның калмавы. Бу эшләнгәннән соң, госел тәһарәте алынган булыр. Матди һәм мәгънәви пакьлеккә ирешелгән булыр.

**Госелнең сөннәтләре**

1. Госел коенуны бисмиллаһ белән башлау.
2. Күңелдән һәм телдән ният кылу.
3. Госелдән алта тешләрне чистарту.
4. Иң башта кулларны юу, шуннан ал һәм арт гаурәт урыннарын юып, шул урыннарны пычраклыклардан пакьләү, шуннан соң тәһарәт алу.
5. Тәһарәт алганнан соң



башка, уң һәм сул җилкәләргә су коеп бөтен тәнне юу.
6. Авыз һәм борынны берәр мәртәбә су белән пакьләү фарыз, ләкин монысын өч мәртәбә кабатлау сөннәт. Һәм шулай ук бөтен тәнне бер мәртәбә юу фарыз, өч мәртәбә юу сөннәт.

**Госел коенуның нинди әдәпләре бар?**

Тәһарәт алуның әдәпләре шулай ук госелнең әдәпләредер. Ләкин госел алган вакытта гаурәт урыннарының ачык булу ихтималы булган өчен, кыйблага таба борылу яхшы күрелмәгән. Госелнең иң мөһим тәртипләреннән берсе - гаурәт урыннарны ябып, беркемгә дә күрсәтмәү. Ләкин беркем булмаган мунчаларда гаурәт урыннарын ачып, кирәк пакьләнүләрне эшләргә мөмкин. Беркем күрмәгән өчен, бернинди куркыныч хәл булмас.

**Госелнең мәкруһлары нәрсә?**

Тәһарәт алган вакытта мәкруһ булган нәрсәләр, госел коенган вакытта да мәкруһ. Артык буларак, госел коену вакытында дога уку һәм кыйблага таба борылу дөрес дип каралмаган. Госел тәһарәтендә бер әгъзага түгелгән су белән башка әгъзаларыбызны да юа алабыз. Чөнки госел тәһарәтендә бөтен тән бер әгъза кебек исәпләнә. Тәһарәт алган вакытта бу ярамас.

**Госел алган вакытта гаурәт әгъзаларыннан берәр пычраклык чыккан булса, госел бозыламы?**

Юк, госел бузылмас, ләкин госелнең тәһарәт булуы бозылыр. Ягъни бу госел белән госелсезлектән пакьләнгән булыр, ләкин намаз уку өчен яңадан намаз укырга мөмкин булмас, чөнки кеше тәһарәтсез.

**Вакытында госел коенмауның берәр куркынычы бармы?**

Госел коенырга тиешле кеше, мөмкин булса, тизрәк юынып алырга тиеш. Тиз генә юына алмаячак кешеләр, нинди намаз арасында госелләрен югалткан булсалар, шул вакыт намазының вакытының бетүенә кадәр кичектерә алалар. Юынмыйча намаз вакытын уздыру дөрес булмас, харам.

**Госел тәһарәте белән бөтен гыйбадәтне үтәргә мөмкинме?**

Әйе, госел коенганнан соң, һәртөрле гыйбадәтне үтәргә мөмкин.

**Нинди хәлләрдә госел фарыз булыр?**

Җөнеплеклектән котылу, хәез һәм нифаз хәлләреннән чыгу өчен.

**Госел ничә өлешкә аерыла?**

Өч өлешкә аерыла.

1. Фарыз госел.
2. Сөннәт госел
3. Мөстәхәб госел.

**Нинди хәлләрдә госел коену сөннәт?**

Шул хәлләрдә госел коену сөннәт була:

1. Җомга намазы өчен.
2. Бәйрәм намазлары өчен.
3. Хаҗ һәм гомрә кылу өчен ихрам киемнәрен кияр алдыннан.
4. Хаҗиларның гарәфә көне Гарәфәттә вәкфә кылу өчен.

**Нинди хәлләрдә госел коену мөстәхәб?**

Шул хәлләрдә госел коену, фарыз яки сөннәт булмыйча, сәваплы эш:

1. Кан алдырганнан соң.
2. Һушын югалтканнан соң үзенә килгәч.
3. Мәетне юу өчен.
4. Изге кичәләрне гыйбадәттә үткәрү өчен.
5. Юлчылыктан өйгә кайтканнан соң.
6. Пакь кием кияр алдыннан.
7. Гөнаһларга тәүбә кылырга теләгән вакытта.
8. Мәккә һәм Мәдинәгә керер алдыннан. Бу изге урынны хөрмәтләү өчен юыну.

Сөннәт һәм мөстәхәб госелләр, тәнне пакьләү яки хөрмәтләү нияте белән кылынганга күрә, боларда авызны һәм борынны юу фарыз түгел. Бөтен тәнне юу җитә.